Республика Татарстан

**СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 57, д.Шарлиарема
423372
Телефон: 4-57-55

Татарстан Республикасы

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, йорт 57, Шәрләрәмә авылы
423372
Телефон: 4-57-55

ОГРН 1121651003671 ИНН/КПП 1636007010/163601001 ОКТМО 92653482

КАРАР №123 16 март 2020 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендә кабул ителгән 33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 321-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман районы прокуратурасының 2009 елның 16 декабрендәге 02-07-01/19 номерлы протесты, Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставына карата Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының «физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 33 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.1.Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан урыннар;»

2) 2.1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.2. хуҗалык төзелешләре яисә корылмалары, аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан;».

2.2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге
Советы Рәисе Н.Н.Хуҗина